Бүгенге санда



Нурлат экстремизмга каршы. 3 бит.


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 18 сентябрь 2015 ел

№ 69 (10598)


19 сентябрьгә һава торышы: алмашынучан болытлы һава, җил көнбатыштан 2-3 м/с; температура көндез +23°С, төнлә +18°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

## ЮБИЛЯРЛАРНЫ КОТЛАДЫЛАР

Сентябрь аенда гына районның өч өлкән кешесе үзләренең 90, 100 яшьлек юбилейларын билгеләп үтте. Бу атнада Октябрина поселогында яшәүче Әминә Беляева һәм Урта Чаллы авылында гомер итүче Нурдидә Хәлиуллинага РФ Президенты Владимир Путин һәм район башлыгы Равил Кузюровның котлауларын ирештерделәр.

## ОЕШТЫРУ СЕССИЯЛӘРЕ ҮТТЕ

Кичә барлык 26 авыл җирлекләренең яңа сайланган советларында оештыру сессияләре үтте. Сессиядә авыл җирлекләре башлыклары, район советына депутатлар сайланды, авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчесен билгеләү турындагы мәсьәлә дә каралды. Шунда ук даими комиссияләр дә формалаштырылды.

## ИКЕНЧЕ УҢЫШ ҖЫЯЛАР

Нурлат картлар йорты теплицаларында икенче уңыш өлгерде. Хәзер өлкәннәр өстәленнән түтәлдән генә җыелган тәзә кыяр, редис, салат, яшел тәмләткечләр өзелми. Ә кыш көнне аларны үзләре үк әзерләп калдырган тозланмалар һәм кайнатмалар алыштырачак.

## КЫЗУ ЭШ ЧОРЫ

Бәрәңге һәм шикәр чөгендере басуларында коры көннәрнең һәр минутын максималь файдаланып эшлиләр. "Сөләйманов Ә.И" КФХсында бәрәңгенең 90 процентлабын алсалар, район буенча татлы тамыр барлык мәйданнарның 34 процентында казылган. Соңгысы быел яхшы уңыш белән сөендерә, бер гектарга уртача уңыш 320 центнер тәшкил итә.


Приглашаем на работу
**ВАХТОВЫМ МЕТОДОМ**
*в Москве мужчин и женщин!*
**Мы предоставляем:**
*Высокую оплату труда*
*Бесплатное проживание*
*Еженедельные авансы*
*Корпоративный транспорт.*
**Звоните: 8 495 646 71 66, 8 966 135 61 88.**
Реклама


# Абхазия – Нурлат: хезмәттәшлеккә күпер салынды



Автор фотосы

РУСЛАН ЛАДАРИЯ БЕЛӘН РАВИЛ КУЗЮРОВ КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЙДЫ

**Чәршәмбе көнне Нурлатта район Советы бинасында Абхазиянең Гудаут районы һәм Нурлат муниципаль районы арасында үзара файдалы хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды.**

Хәзер Нурлатның Төркиянең Җәйһан шәһәреннән тыш, тагын бер кардәше – Абхазиянең Гудаут районы барлыкка килде. Абхазия белән Нурлатның якынаюы барлык өлкәләргә дә кагылачак.

Абхазиянең Гудаут районы хакимияте башлыгы Руслан Ладариянең Нурлатка визиты – районның социаль, сәнәгый потенциалы белән танышу максатыннан иде.

Гудаут районы башлыгының Татарстан, Нурлатның уңышларын шәхсән күрү теләге күптәннән булган.

– Район, шәһәр һәм аның социаль, икътисади һәм сәнәгый потенциалы белән танышу ике район арасында җылы мөнәсәбәтләр урнаштыру теләген тагын да ныгытты, – диде Абхазиянең Гудаут районы администрациясе башлыгы Руслан Ладария визиты ахырында. – Мин көткәнгә караганда да күбрәк уңышлар күрдем сездә, безгә өйрәнер нәрсәләр күп. Алга таба тәҗрибә уртаклашу ягыннан очрашулар тагын булыр дип өметләнәм. Бездә дә күрсәтер нәрсәләр бар, аерым алганда, тарихи урыннар. Ике көнлек визит барышында Нурлатта игелекле кешеләр белән танышу миндә яхшы тәэсирләр калдырды. Нурлат һәм Гудаут районнарының проблемалары охшаш, әмма Нурлатта социаль проблемалар хәл ителгән, сез бу яктан алда барасыз. Безнең үзара файдалы хезмәттәшлек исә ике район арасында спорт, мәдәният, туризм һәм сәнәгать өлкәсендә зур плюс булачак. Алга таба район башлыгы Равил Кузюровны җавап визиты белән үзебезнең районга чакырам.

– Нурлат һәм Абхазия халыклары арасындагы мөнәсәбәтләрне ныгыту һәм киңәйтүдә барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәчәкбез, – диде район башлыгы Равил Кузюров килешүгә кул куйганда.

Ике район арасындагы дуслыкка беренче адымнар ясалды. Аның алга таба үсеше безнең игътибарда булачак.

**Зилия ӘКСАНОВА**

(Теманың дәвамы – 2 нче биттә).

КЫСКАЧА

## Кулланучы һәрчак хаклы

Ел башыннан Нурлат Дәүләт алкоголь инспекциясенә телдән һәм язма 95 мөрәҗәгать кергән. Аларның бары берсе генә көнкүреш хезмәтләре күрсәтүгә кагылышлы, калганнары сәүдәгә туры килә. 8 ай эчендә яраклылык срогы чыккан, әзерлек һәм яраклылык вакыты турындагы мәгълүматы булмаган продукция сатуның 9 очрагы ачыкланган. Сатудан 22 мең сумлык сыйфатсыз азык-төлек товарлары алынган.

## Конвертта булырга тиеш түгел

Кичәге көнгә районда эш бирүчеләр һәм хезмәткәрләр арасында 2265 килешү төзелгән. Хезмәт хакын конверт формасында бирү, хезмәт эшчәнлеген хезмәт килешүеннән башка рәсмиләштерү фактлары буенча мөрәҗәгатьләр кабул итү 2-06-69, 2-46-30 "кайнар линия" телефоннары буенча дәвам итә.

## Ярминкәгә җыеналар

Районның авыл хуҗалыгы житештерүчеләре бу шимбәдә Казанга ярминкәгә барырга җыена. Районның эре хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүче предприятиеләре, фермерлар, шәхси ярдәмче хуҗалыклар, авыл җирлекләре Агросәнәгать паркында 40тан артыграк нокта сәүдә итәргә ниятли.

## 5нче сыйныфтан – аттестация

Районның 539 5нче сыйныф укучысы рус теле һәм математика фәннәреннән башлангыч диагностика узачак. Аттестация районның барлык мәктәпләрендә рус теленнән 30 сентябрьдә, математикадан 2 октябрьдә үтәчәк.

# БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## Рәхмәт белдерәбез

Сентябрьнең җылы көннәрендә кояшыбыз сүнде, көннәребез караңгыланды – аяусыз язмыш арабыздан якын кешебез Илназ Илгиз улы Мөбарәкшинны алып китте. Аны кадерләп соңгы юлга озатканда янәшәбездә булган "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") газетасы редакциясе коллективына, пенсионерларына, элеккеге хезмәттәшләребез һәм җитәкчебез Сәкинә Нурулла кызы Хәйруллинага рухи һәм матди ярдәм күрсәтүләре өчен чиксез рәхмәтләребезне белдерәбез. Бу көннәрдә хәлебезгә кереп, ярдәм кулы сузган һәркемгә – "Нурлат" ТРКсы коллективы, район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт, мәдәният бүлекләре коллективларына, район спортчылары һәм барлык спорт оешмаларына, "Коммунальник" ТСЖсы, шәһәрнең 1нче, балалар сәнгать мәктәпләре коллективлары һәм ата-аналар комитетларына, барлык туганнарга, якыннарга, Биккол авылы халкына, күршеләргә, дусларыбыз, укучыларыбызга, Илназның дусларына һәм башка бик күпләргә рәхмәтләребезнең чиге юк. Ходай сезгә югалту кайгылары бирмәсен, якыннарыгыз һәрчак янәшәгездә булсын.

**Олы рәхмәт белән балалары, тормыш иптәше, әнисе һәм барлык туганнары.**

### НЕДВИЖИМОСТЬ

*жилой дом, ж/д. Т. 8-927-676-25-75.
*дом, ул. Московская. Т. 8-937-599-75-94.
*дом. Т. 8-987-421-39-97.
*дом. Варианты. Т. 8-919-684-40-03.
*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 3 этаж, 1350тыс. Т. 8-927-439-69-54.
*готовый бизнес: магазин «Калейдоскоп», магазин «Спорттовары и игрушки». Т. 8-927-049-26-51.
*1-комнатная квартира, мкр. Яшлек. Т. 8-927-473-25-64.
*4-комнатная квартира, ул. Нурлатская, 10. Т. 8-986-711-43-58.
*дом, ж/д. Т. 8-927-439-65-16.
*3-комнатная квартира по ул. Кариева. Т. 8-927-457-40-44.
*2-комнатная квартира, с/з. Т. 8-927-414-73-97.
*частный дом по ул. 70 лет Нурлатскому району, гараж на 2 машины, баня, хозпостройки: Имеется колодец, большая теплица, душевая в огороде. Т. 8-937-774-55-49.
*дом в д.Якушкино, газ, вода, свет. Участок 43 соток. Т. 8-912-757-13-80.
*срочно 2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 19. Т. 8-927-675-37-23.
*срочно 2-этажный дом, ул. Ахметова, 32, черновая отделка. Т. 8-927-409-48-88. *2-комнатная квартира. Т. 8-927-447-65-07.
*участок под гараж, фундамент, ул. Нурлатская. Т. 8-927-243-65-08.
***1-комнатная квартира,** ул. Советская, **2-комнатная квартира,** ул. Заводская, ул. Кариева, **3-комнатная,** ул. К.Маркса, дома: ул. Кутузова, с. Фомкино, с. Мамыково, с. Бутаиха, **земельный участок,** Тарн Варн, 17,5 соток. Т. 8-9274-222-456.
*элитный коттедж, 6,2 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, с. Биляр Озеро, 130 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, д. Берлик, 100 кв.м, 350 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом (д. Русская Менча, кирпичный, 1 млн. руб., 100 кв.м) или обменивается на квартиру в г.Нурлат. Т. 8-937-610-48-70.
*недостроенный дом, ул. Звездная, 100 кв.м, кирпичный, 930 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*земельный участок, д. Пушкино, 10 соток, 90 тыс.руб. (ИЖС). Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Полевая, 11, 80 кв.м, 1,450 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*жилой дом, ул. Декабристов, 57, 50 кв.м, 750 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 2 этаж, 47 кв.м, 1,1 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 1 этаж, 44 кв.м, ремонт, 1 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, с/з, 50 кв.м, 1 этаж, ремонт, 900 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная новая квартира, мкр. ж/д, 50 кв.м, 2 этаж, 1250000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мансарда, центр, ул. Школьная, 50 кв.м, 920 тыс. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, мансарда, ул. Ленинградская, общежитие, 50 кв.м, 650 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*2-комнатная квартира, ул. Садовая, 5 этаж, 50 кв.м, балкон, 850 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, 22 кв.м, 1 этаж, без ремонта, мкр. Яшлек, 500000 руб. Т. 8-937-610-48-70.
*1-комнатная квартира, 3 этаж, 34 кв.м, без ремонта, мкр. Яшлек. Т. 8-937-610-48-70.
*3-комнатная квартира, 5 этаж, мкр. Яшлек, 60 кв.м, 1,2 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*комната в общежитие, ул. Ленина, 45, 210 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*комната в общежитие, ул. Нефтяников, 2, 210 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.
*элитный коттедж, ул. Победы, 5,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.
*земельный участок, ул. Кузнецова, 9 соток, 150 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«Лада Приора», универсал, 2013 г/в, цвет белый, 265 тыс. Т. 8-908-348-90-47.
*МТЗ-82. Т. 8-927-676-04-67.
*самодельный мини-трактор с прицепом, 85000 руб., возможен торг. Т. 8-9874-099-348.
*«Шевроле Спарк», 2009 г/в, пробег 42000 км. Т. 8-927-434-47-05.
*«ВАЗ-21074», 2010 г/в, цвет черный, 110 тыс.руб. Т. 8-927-417-51-78.
*«Ниссан Ноте», 2011 г/в. Т. 8-927-425-63-80.
*«Приора», 2009 г/в. Т. 8-927-442-09-00
*«КамАЗ» сельхозник. Т. 8-927-492-32-74.
*тягач «МАЗ543205-226», 2007 г/в. Т. 8-960-063-95-91.
*«УАЗ-3303», бортовой, 1993 г/в, 50000 руб. т. 8-917-263-99-32.

### ДРУГОЕ

*перегной, чернозем, грунтощебень, глина, битый кирпич, бут, ПГС. Т. 8-937-286-82-43.
*корова, один отел. Т. 8-937-296-32-27.
*печи для бани, баки. Т. 8-927-047-39-53.
*новый унитаз, дешево. Т. 8-927-676-81-57.
*сахар-2230, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.
*бычки, телята разного возроста. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.
*дрова. Т. 8-987-213-32-95.
*бычки, молодняк. Т. 8-937-453-40-91.
*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.
*бычки молодняк. Т. 8-937-930-89-29.
*песок, бут, ПГС, цемент, щебень, чернозем. Т. 8-927-247-94-76.
*бычки молодняк. Т. 8-927-880-12-83.
*овцы. Т. 8-927-200-18-27.
*овцы, бараны, ярки. Т. 8-927-766-94-17.
*куры, утки. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.
*бут, ПГС, песок, перегной. Т.: 8-927-675-54-96, 8-917-248-21-66.
*ПГС, бут, песок. Т. 8-987-283-18-34.
*картофель. Т. 8-927-405-70-89.
*чернозем, перегной, грунтощебень, бут. Т. 8-927-463-63-17.
*картофель, лук, морковь. Т. 8-927-472-60-73.
*картофель. Т. 8-927-241-58-83.
*козочка. Т. 8-927-455-24-78.
*теленок, 2 месяца. Т. 8-927-723-70-36.
*помидоры. Т. 8-937-593-08-66.
*картошка, дешево. Т: 8-917-912-79-66. 8-927-428-04-52.
*перепелиные яйца, доставка. Т. 8-927-671-67-97.
*шифер, б/у, дешево. Т. 8-927-242-76-55.
*картофель. Т. 8-937-285-99-31.
*дешево набор кухонной мебели, шифоньер. Т. 8-917-897-95-27.
*сруб бани 5-стенка, новый, недорого; картошка мелкая. Т. 8-927-413-05-92.
*картофель. Т. 8-937-291-43-87.
*козье молоко. Т. 8-927-443-76-66.
*бараны, овцы на Курбан байрам, д. Чув.Менча (зерноток).
*перегной, 2000 руб. Т. 8-937-600-49-27.
*силикатный кирпич, 5 руб. Т. 8-937-600-49-27.
*дрова (горбыль), 3000 руб. Т. 8-937-600-49-27.
*ворота (2,5х2,5), банные камни. Т. 8-927-406-05-23.
*угловой диван и кресло. Т. 8-927-035-54-18.
*мягкий угол, б/у. Т. 8-927-458-64-54.
*корова, 1 отел, красно-белой масти. Т.: 8-937-999-52-44, 8-937-066-37-31.
*кирпич в ассортименте, газоблоки; услуги манипулятора. Т.: 8-927-401-51-91, 2-03-43.
*овцы на Курбан-байрам, недорого. Т. 8-937-592-05-85.
*козочки суягные. Т. 3-60-47.
*теленок, 7 месяцев. Т. 8-929-725-94-66.
*картошка, козлята, коляска-трансформер. Т. 8-987-189-59-20.

Стоматология
ООО «МЕТА-ДЕНТА»
- ТЕРАПИЯ от 650 руб.
- ОРТОПЕДИЯ-ПРОТЕЗИРОВАНИЕ
- УДАЛЕНИЕ.
Ул. К.Маркса, 2, тел.: 2-00-92, 8-927-489-99-96;
ул. Советская, 141 (бывший клуб нефтяников),
тел.: 2-23-00, 8-927-45-000-26.
Имеются противопоказания.
Необходима консультация специалиста.
Реклама




### ТРЕБУЕТСЯ

*администратор с мед.образованием в стоматологическую клинику. Прием по итогам собеседования. Т. 8-927-043-16-23, после 19.00.
*в ООО «Перспектива» водители, крановщик. Справки по тел.: 2-58-21, 2-58-22, по адресу: г.Нурлат, ул. Заводская, 1.
*организации упаковщики (-цы) и рабочие для физической работы. Т. 8-927-437-18-18 (до 18.00).
*продавец в продуктовый магазин. Т.: 8-927-443-80-43, 8-919-644-51-41.
*разнорабочий. Т.: 2-78-66, 8-937-770-11-72
*электромонтеры. Т. 8-917-398-26-41.
*в ООО «Перспектива» охранник. Справки по т.: 2-58-21, 2-58-22, по адресу: г. Нурлат, ул. Заводская, 1.
*маникюрист. Т. 8-927-421-80-33.
*медицинский работник (-ца) стоматологии, г. Нурлат. Требование: действующий сертификат «сестринское дело в стоматологии». Т. 8-927-266-46-26.

### РАЗНОЕ

*электрик. т. 8-929-725-66-28, 8-939-732-05-01.
*выравнивание стен, обои, плитка. Т. 8-927-455-25-35.
*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.
*репетиторство 8-11 классы. Подготовка к ОГЭ и ЕГЭ по химии. Т. 8-927-672-76-36.
*услуги электрика. Т. 8-937-614-70-15.
*ремонт пластиковых окон. Т. 8-927-249-54-24.
*ремонт стиральных машин. Т. 8-927-468-16-31.
*установка окон, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.
*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.
*ежедневно Нурлат-Самара автовокзал, глазные клиники. Т. 8-927-031-29-33.
*кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.
*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.
*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.
*сантехника (вода, канализация, отопление). Т. 8-937-526-56-86.
*вспашка земли. Т. 8-927-481-29-70.
*перегной, песок, ПГС, глина от 3т. Т. 8-927-424-02-83.
*ищу работу программистом, системным администратором. Т. 8-927-485-70-65.
*ремонт, настройка компьютеров, ноутбуков, Интернета, Wi-Fi. Т. 8-937-0051-451.
*ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.
*выравнивание стен, потолков, обои. Т. 8-937-288-61-40.
*копаем, чистим колодцы. Т. 8-987-274-95-46.
*татуаш, маникюр, педикюр, макияж. Т. 8-927-402-25-12.
*отдам щенят в хорошие руки. Т. 8-927-412-23-68.
*грузоперевозки. Т. 8-927-406-83-84.
*отделочные работы. Т. 8-937-620-00-60.
***грузоперевозки, «ГАЗель», 4.20 тент. Т. 8-927-442-38-10.**
*обшиваем дома, кроем кровлю и другие строительно-ремонтные работы. Т. 8-927-422-26-33.
*выполняем земляные и бетонные работы, копаем колодцы под ключ. Т. 8-927-481-51-72.
*ремонт, настройка компьютеров, планшетов, Wi-Fi, Интернета. Т. 8-937-0051-451.

### СНИМУ

*1-комнатную квартиру. Т. 8-927-671-49-57.
*1-комнатную квартиру по ул. Козлова или Гагарина на долгий срок. Т. 8/-987-063-61-99.
*срочно 2, 3-комнатную квартиру, недорого. Т. 8-927-246-85-05.

### ПОТЕРИ

*утерянное водительское удостоверение 16 ТО №007184, выданное на имя Минасхата Мидхатовича Маняпова, считать недействительным.



✓Оформление по ТК РФ
✓Иномарки, постоянное обновление
✓Высокий уровень зп
✓Корпоративная связь
✓Страховка
✓Ремонт в СЦ
✓При приеме обязательно наличие у водителя карты для тахографа ЕСТР
ЗВОНИТЕ: +7-962-567-36-23
ТЕЛ. В НАБЕРЕЖНЫХ ЧЕЛНАХ: +7(8552)77-82-82
*Делко. Реклама

12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә

**21 СЕНТЯБРЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.
**23 СЕНТЯБРЬ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.
**25 СЕНТЯБРЬ**
**"Нурлат хәбәрләре".**
**"Сиңа дигән җырым",** музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **22, 24, 26нчы сентябрьдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**М-н «КОЛЬЦО»**
- в ассортименте кирпич;
- газобетон;
- блок доломитовый;
- перемычки;
- кольца колодезные и канализационные с установкой;
- цемент, клей д/газобетона;
- теплицы;
**- ДОСТАВКА!**
**г.Нурлат. мкр Западный («Афганский»).**
**8(4345) 280-57; 8-9276-755-091.**

**ПЛАСТИКОВЫЕ ОКНА «KRAUSS»**
**С 1 января по 31 декабря 2015 г. при заказе 5 окон. 6-е в подарок***
**Деревенские окна по 2000 руб.**
**Откосы, подоконники, москитные сетки.**
**Работаем по всему Татарстану.**
**Рассрочка без % (предоставляет ИП Ахметов Ф.Ф.).**
***подробности по т.: 8-9274-000-606, 8-9272-449-000.**
**ИП Ахметов Ф.Ф.**

## ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Тагын бер солдат-фронтовик, Бөек Ватан сугышы ветераны, Түбән Нурлат авылында туып-үскән **Шәфыйкъ Сафиулла улы Әбҗаппаров** якты дөньядан китте.

1943 елның гыйнвареннан 1945 елның декабренә кадәр ул Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, Днепрны форсировкалаудан алып Праганы азат итүгә кадәр барып җитә. Украинаны азат иткәндә ике тапкыр каты яралана. Сугыштан соңгы тормышын ул Татарстанның авыл хуҗалыгын үстерүгә багышлый. Авыл хуҗалыгы культураларыннан зур уңыш алуы өчен аңа "Россия Федерациясенең атказанган агрономы" дигән исем бирелә. Шәфыйкъ Сафиуллович ике тапкыр СССР ВДНХсында катнаша. Ул укымышлы, тәрбияле кеше, күпләргә остаз булды, кайгыртучан һәм яраткан әти иде. Ул безнең күңелләребездә мәңге сакланыр. Авыр вакытларыбызда ярдәм иткән һәм кадерле тормыш иптәшем, әтиебез, бабабызны соңгы юлга озатканда булышкан һәркемгә – барлык туганнарыбыз, якыннарыбызга, Түбән Нурлат халкына, 2нче мәктәп коллективына, күршеләргә зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

**Хатыны, балалары, оныклары.**

## Кайгы уртаклашабыз

"Дуслык" район газетасының талантлы журналисты **Илназ Илгиз улы Мөбарәкшинның** вакытсыз вафаты сәбәпле, мәрхүмнең тормыш иптәше Лилиянең, балалары Булат белән Камилнең һәм якыннарының тирән кайгыларын уртаклашам. Хәсрәтле көннәрдә сабырлык телим.

**Сания Фәтхетдинова,** Яңа Әмзә авылы

Нурлат шәһәренең 4нче мәктәбе администрациясе һәм коллективы, әтисе **Фәйзерахман Әхмәтҗан улының** вафат булуы сәбәпле, мәктәп директоры Солтан Фәйзерахман улы Әхмәтҗановның тирән кайгысын уртаклаша, хәсрәтле көннәрендә сабырлык тели.

## ЭКСТРЕМИЗМГА – ЮК!

# Каршы торырга һәрчак әзерләр



**2009 ел. 17 август – Назраньда теракт, 25 кеше үлә, 136 кеше тән җәрәхәте ала.**
**27 ноябрь – "Нева экспрессы" поезды һәлакәте теракт буларак бәяләнә. 28 кеше үлә, 95е яралана.**
**2011 ел. Мәскәүдәге Домодедово аэропортында террорчы бомба шартлата. 37 кеше һәлак була, 130ы тән җәрәхәте ала.**
**2013 ел. 29 декабрь – Волгоград вокзалында шартлау. 18 кеше һәлак була, 40ы яралана.**
**2015 ел. 14 сентябрьдә Тольятти каучук заводында шартлау була. Бер кеше үлә, ике кеше хастаханәгә озатыла...**

Терактларда һәрвакыт бер гаепсез кешеләр һәлак була. Экстремистларның һәм террорчыларның алдан уйланылган җинаятьләре көтмәгәндә һөҗүм итүгә исәпләнгән дә инде. Шуңа күрә мондый күренешләргә каршы тору өчен, стратегик мөһим объектлар төрле профилактика чаралары кулланалар. Оешма һәм учреждениеләрдәге стендлар, коллектив өйрәнү тренировкалары, янгын службасының предприятиеләрдәге эвакуация юлларын тикшерүе һәм башка чаралар – болар барысы да гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрне дөрес карарлар кабул итәргә өйрәтүгә юнәлдерелгән.

Узган атнада "Нурлатнефтепродукт" базасында "Татнефтепродукт" холдинг компаниясе структур подразделениеләре ирекле янгын дружиналарының хәрби әзерлек смотр-ярышы булып узды.

– Без куркыныч җитештерү объектында эшлибез, һәм бу ярыш – безнең өчен бик әһәмиятле чара, – диде предприятиенең баш инженеры Василий Гаврилов. – Экстремизм һәм террорчылык очраклары булганда, дөрес эш итәргә өйрәнү өчен бездә барлык алымнар да кулланыла.

Биредә холдинг компаниясе структур предприятиеләреннән янгын машиналары һәм янгын мотопомпалары булган 10 команда көч сынашты. Мондый смотр-ярышларның максаты булып гамәли эшчәнлеккә әзерлекне билгеләү, ирекле янгын дружинасы әгъзаларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрү, профессиональ янгын сүндерүчеләр белән предприятиенең ирекле янгын дружиналарының бердәм эш итүен көйләү тора. Ярышлар 5 этапта узды. Беренчесе – хәрби кием-салымны кию. Бу беренче карашка гына җиңел булып тоела. Ә катнашучыларга санаулы секундлар эчендә старт линиясеннән янгын постына чабып барып, брезент куртка, җилкә каешлы чалбар, карабинлы каеш, битлекле каска һәм пелерина, бияләй кияргә кирәк. Барысы да җентекләп тикшерелә: хәрби киемнең барлык төймәләре дә каптырылганмы, куртка якасы күтәрелгән һәм турайтылганмы, каеш борылмаганмы... Гомумән, жюри әгъзалары һәр биремнең үтәлешен җентекләп тикшерделәр, катнашучылар да ярышларга җитди карадылар: беркемнең дә штрафлы секундлар аласы килмәде. Алга куелган бурычларны барысы да үтәде, ә нурлатлылар, биремне 25 секунд эчендә башкарып, иң яхшылар буларак танылдылар. Беренче этаптагы уңыш, яисә үз җирләрендә чыгыш ясау булыштымы, "Нурлатнефтепродукт" командасы башка этапларда да лидерлыкны бирмәде. Әмма аннан бер атна элегрәк Казанда узган ягулык салу станцияләре операторлары арасындагы конкурста Нурлат нефтебазасының иң яхшы нәтиҗә күрсәтүен искә алсак, мондый чараларны үткәрү урынының әһәмияткә ия булмаганын күрербез. Иң мөһиме – үз эшеңне яхшы белү. Мондый стратегик предприятиедә бу икеләтә әһәмиятле. Шуңа күрә конкурста катнашучы "Нурлатнефтепродукт" хезмәткәрләре җитезлек тә, осталык та күрсәттеләр. Икенче этап – тревога буенча җыену һәм янгын автомобилендә юлга чыгу өчен алар янә иң яхшы вакыт – 26 секунд кына сарыф иттеләр. Су, янгын техникасыннан һава-механик күбек сиптерүдә дә яхшы нәтиҗә күрсәттеләр. Шулай итеп, нурлатлылар беренче урынга чыктылар.

– Бу чара безнең ирекле янгын дружиналарыбызның укуына нәтиҗә ясау, – диде ярышлардан соң "Татнефтепродукт холдинг компаниясе" ААҖ генераль директоры Рөстәм Сабиров. Шунда ук җиңүгә ирешкән нурлатлылар адресына мактау сүзләрен дә өстәде. – Нефтебаза әйбәт торышта, без аның теләсә нинди көтелмәгән хәлгә әзер булуын күрдек.

Янгын сагының Нурлат гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин әйтүенчә, экстремизм һәм терроризмны профилактикалау буенча чаралар район һәм шәһәрнең башка объектларында да үткәрелә.

– Районда терроризмга каршы комиссия эшли, аны район башлыгы Равил Кузюров җитәкли. Хокук саклау структуралары, МЧС, дини оешмалар вәкилләре катнашында үткән утырышларда Россиядә, республикада һәм районда килеп туган проблемалы мәсьәләләр карала. Стратегик әһәмиятле, массакүләм халык булган объектлар җитәкчеләренә әлеге объектларны саклау, предприятиенең барлык периметры буенча видеокүзәтү кертү, тревога сигналы кнопкасын булдыру кебек бурычлар йөкләнгән. Болардан тыш, мондый объектларда өйрәнү тренировкалары да үткәрелә. Болар барысы да шәһәрдә һәм районда экстремизм һәм терроризм очракларына юл куймас өчен эшләнә.

# Өйрәнү эвакуациясе ярдәм итә

Шәһәрнең 2нче мәктәп укучылары дәрес уртасында яңгыраган бер озын һәм ике кыска сигналны тәнәфескә чакырган кыңгырау тавышы белән бутамыйлар. Бу – эвакуация сигналы.

– Мәктәптәге өйрәнү эвакуациясе – теләсә нинди гадәттән тыш хәлләрдә балаларны саклау алымнарыннан берсе, – ди әлеге күренешне күзәтеп торган Нурлат шәһәренең ОНД баш белгече Әлмарис Талипов.

3, 4, 6, 7нче сыйныф укучылары укытучы озатуында сыйныф бүлмәсеннән тиз генә чыктылар һәм эвакуацион чыгу юлларына таба юнәлделәр. Бу мәктәптә алар 6ау, һәркайсына номер сугылган, иң әһәмиятлесе – һәр сыйныф эвакуация вакытында үз чыгу юлын белә. Шуңа күрә укучылар арасында каушап калу күзәтелми, алар тыныч, һәр сыйныф бер-бер артлы мәктәптән чыга бара. Мәктәп ишегалдында да ыгы-зыгы күренми – барысы да тезелешеп, җыелу урынына ашыгалар. Мондый чараларның биредә даими үткәрелүе күренеп тора.

– Без чиреккә бер тапкыр укучылар белән өйрәнү эвакуациясе уздырабыз, – ди мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык өчен җаваплы Гүзәл Бурлакова.

Бу көнне кече һәм урта сыйныф укучылары иң яхшы вакыт күрсәттеләр – шартлы куркыныч янау урынын 2 минут ярым эчендә ташлап киттеләр. Көз-яз көннәрендә җыену өчен 3 минут, кышын 5 минут бирелә. Сүз уңаеннан, кыш көне икенче смена укучылары арасында өйрәнү эвакуациясе тулы караңгылыкта диярлек үткәрелә – караңгы иртә төшә бит. Бу вакытта балалар стенадагы һәм эвакуацион чыгу юллары өстендәге күрсәткечләргә карап ориентлашалар.

– Өйрәнү эвакуациясе вакытында алынган күнекмәләр каушап калмаска ярдәм итә. Уку елының беренче көннәрендә без балалар белән куркынычсызлык буенча инструктажлар үткәрдек, – диде Гүзәл Бурлакова. – Өлкән сыйныф укучылары белән сыйныф сәгатьләре вакытында яшьләр экстремизмы һәм аның нәрсә белән янавы хакында сөйләшәбез. Безнең мәктәптә 10га якын милләт балалары белем ала. Укучыларда без төрле милләт кешеләренә ихтирам, толерантлык сыйфатлары тәрбиялибез. Хәзер "Экстремизмга – юк!" айлыгы бара, һәм без МЧС белән берлектә төрле чаралар үткәрәбез. Балаларга шикле предмет тапкан очракта үз-үзләрен ничек тотарга, таныш булмаган кешеләр үтенече белән мәктәпкә нинди дә булса пакетлар, төргәкләр алып килергә ярамаганлыгы хакында аңлатабыз.

Район мәктәпләренә МЧСның игътибары зур. Әлмарис Талипов әйтүенчә, эвакуация юллары, ут булмаганда фонарьларның, кисәтү билгеләренең булуы җентекләп тикшерелә.

– Шундый тикшерүләр вакытында мәктәп территориясендә чит транспорт чараларының булмаска тиешлеген аңлатабыз, яктыртуга игътибарны юнәлтәбез. Уку елы башына район мәктәпләре куркынычсызлык ягыннан яхшы әзерләнгәннәр, – ди ул. – Хәзер уку-укыту учреждениеләрендә "Укчы-мониторинг" программа-аппарат комплексын урнаштыру дәвам итә. Әлеге комплекс, мәктәптә янгын чыккан очракта, 125нче янгын частенең диспетчер службасында да автоматик рәвештә янгын сигнализациясе сигналы эшләп китүен тәэмин итә. Райондагы 43 мәктәпнең 20сендә бу комплекс урнаштырылган инде, ноябрь азагына кадәр ул башка мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында да булачак.

**Язмаларны Сирень СӘМӘРХАНОВА әзерләде**

## ШАРТЛАТКЫЧ ҖАЙЛАНМА ТАПКАН ОЧРАКТА



- *Шикле предметка юлыккан очракта, һичкичекмәстән эчке эшләр органнарының, ФСБ, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлекләренең кизү службаларына, шәһәр хакимиятенең оператив кизү торучысына хәбәр итәргә. Тел.: 2-22-72, 112.*
- *Тапкан предметка якын килмәскә, кул белән тотмаска, башкаларны аның янына җибәрмәскә.*
- *Радиошартлаткычны хәрәкәткә китерергә сәләтле радио элемтәсе, кәрәзле телефоннар һәм башка радио чараларын куллануны булдырмаска.*
- *Хокук саклау органнары вәкилләренең килгәнен көтәргә һәм шикле предметның урынын күрсәтергә.*
- *Шартлау куркынычы булган предметны аның табылу урынында бары тик МВД, ФСБ, МЧС белгечләре генә зарарсызландыра ала.*

## ӘГӘР СЕЗНЕ ЗАЛОЖНИКЛЫККА АЛСАЛАР



- *Үз-үзегезне кулга алыгыз, тынычланыгыз, паникага бирелмәгез.*
- *Сезне урлаучыларга карата нәфрәт һәм илтифатсызлык күрсәтмәгез.*
- *Баштан ук террористның барлык күрсәтмәләрен үтәгез.*
- *Үз-үзегезне тотышыгыз белән террористларның игътибарын җәлеп итмәгез, актив каршылык күрсәтмәгез.*
- *Әгәр качу уңышына тулы ышанычыгыз булмаса, качарга тырышмагыз.*
- *Үзегезне начар хис итүегез турында әйтегез.*
- *Террористлар турында күбрәк мәгълүмат истә калдырыгыз.*
- *Үзегезнең кайдалыгыгызны билгеләргә тырышыгыз.*
- *Рухи һәм физик активлыкны саклагыз. Шуны истә тотыгыз: хокук саклау органнары сезне коткару өчен барысын да эшли.*
- *Ашаудан баш тартмагыз. Ул көч һәм сәламәтлекне сакларга ярдәм итә.*
- *Тәрәзә, ишектән, террорчыларның үзләреннән ераграк урын алыгыз. Бу бинаны штурмлау башланган очракта, җинаятьчеләргә юнәлгән снайпер пуляларыннан саклану өчен кирәк.*
- *Бинаны штурмлаганда битегез белән аска, кулларыгызны баш артына куеп, идәнгә ятыгыз.*

## ТЕРАКТ КУРКЫНЫЧЫ ВАКЫТЫНДА



- *Ашыгыч эвакуациягә әзерләнегез. Моның өчен сумкага документларыгызны, акча, кыйммәтле әйберләрегезне, бераз ашамлыклар тутырыгыз.*
- *Балкон һәм лоджиялардән ягулык-майлау һәм җиңел янучан материалларны алыгыз.*
- *Беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен йод, бинт, мамык һәм башка медчаралар әзерләгез.*
- *Кешеләр күп җыелган урыннарны әйләнеп узыгыз.*
- *Җәмәгать транспортларыннан сирәк кулланыгыз.*
- *Балаларны һәм олы кешеләрне башка торак пунктка озату кулай.*
- *Радио һәм телевизор һәрвакыт эшләп торсын.*
- *Ашамлыклар һәм су запасы булдырыгыз.*
- *Хокук саклау органнарына ашыгыч мәгълүмат җибәрү өчен телефоннар исемлеге һәрвакыт кул астыгызда булсын.*

# Язмышын үзе сайлаган

ҺӨНӘРМӘННӘР

**Нурлатның ветеринария лабораториясе асылда үз хуҗалыгында мал-туар, шәһәрлеләр арасында йорт хайваннары асраучыларга билгеле.**

Лия Яковлева – ветлабораториядә иң тәҗрибәле хезмәткәрләрнең берсе, аның 35 еллык стажы бар. Бирегә ул Буа ветеринария техникумын тәмамлагач килгән, ул чагында аңа нибары 20 яшь булган. Ә һөнәрен үз теләге белән, аңлап сайлаган.

– Үзем Иске Иглайдан, әтием ветеринар булып эшләде, шуңа да нинди юл сайлавымны бик яхшы белдем, – дип хатирәләрен барлый бүген Лия Ильинична. Хәер, аннан яхшы ук педагог да чыккан булыр иде: мәктәпне тәмамлагач, аны нәкъ менә укытучылыкны сайларга үгетлиләр, чөнки әнисе дә мөгаллимә булган бит. Әмма Лия Яковлева үгетләргә бирешмичә һәм язмышын үзе теләгәнчә сайлый һәм моңа бер дә үкенми, коллективта хөрмәт итәләр һәм хезмәтенә намуслы караганга кадерлиләр дә аны, ә бу бик мөһим нәрсә.

Лия Яковлеваның ветлабораториядәге бурычы җаваплы. Хайваннар арасында авыруларга юл куймау өчен тырыша ул. Серология бүлеге лаборанты буларак, елына ике тапкыр кан тикшерү белән шөгыльләнә.

– Районлагы терлекләрнең барысы да – шәхси сектордагылар да, хуҗалыкларныкы да безнең өстә, – дип сөйли Лия Ильинична. – Малның сәламәтлек торышын урында ук ачыклау һәм авыруларга юл куймау өстендә эшлибез. Хәзер, мәсәлән, лейкозга тикшерәбез. Бу авыру ачыкланган очракта аның таралуына юл куймау өчен башкарыла. Без үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәләре буенча табиблар эшли башлый.

Аларның эшендә бар да төп-төгәл. Бәлкем, шуңадыр да, районда хайваннар арасында йогышлы авырулар юк. Мисал өчен, узган ел Кукмара районында себер түләмәсе табылган. Нурлат ветеринарлары тиз арада чаралар комплексын кырыслаталар, кабат вакцинация үткәрәләр, һәм әлеге авыруның безнең районда да барлыкка килүенә юл куймыйлар.





ХЕЗМӘТ ВЕТЕРАНЫ ЛИЯ ЯКОВЛЕВА ЯРАТКАН ЭШЕНӘ 35 ЕЛ ГОМЕРЕН БАГЫШЛАГАН

Хезмәт кешене бизи, диләр. Әгәр дә кеше 8 сәгатьлек эш кысаларына гына салынмаса, бу, чыннан да, шулай. Мәсәлән, Лия Ильинична үз йорты белән тора, һәм үзенә дә, башкаларга да тик утырырга бирми. Тормыш иптәше белән аны селекционерлар диярге дә була әле. Дөрес, үзләре тыйнаклар, бу хакта сөйләмиләр. Әмма Лия Ильиничнаның коллегалары әйтүенчә, аларда ел саен яңа сорт виноград пәйда була икән. Яковлевлар исә үзләре бу эшне сортларны яңарту дип атыйлар. Хәзер, мәсәлән, 5 сорт виноградтан мул уңыш алалар, ә узган ел үрчеткән 3 яңа сорт әлегә яшьләр, киләсе елдан алар да җимешләре белән сөендерер, дип торалар. Лия Ильинична виноград үстерүне иренең уңышлары дип санаса, чәчәкләр – аның яраткан шөгыле. Өйдә декоратив гөлләр балкып утыра, бакчасы да чәчәкләргә күмелгән.

– Роза, георгинны бик яратам, – ди шөгыле турында Лия Яковлева. Монысын аңлавы кыен түгел: аларның бакчаларында 11 сорт георгин бар. Розалары да сокландырырлык. Кызыл, ак, ал төстәге 7 сорт арасында куаксыманнары да, үрмәлеләре дә җитәрлек. Ә менә бакчасындагы күпме чәчәк барлыгын әйтергә кыенсына, санап бетерерлек түгел инде, дип елмая гына.

Җәй кем өчендер ял чоры, ә кайберәүләр мәшәкатьләргә чума, һәм бер көнне дә бушка уздырмаска тырыша. Әнә, Лия Ильинична да иртә яздан кара көзгә кадәр бакчасында мәш килә. Кышкылыкка әзерләнмәләр ясау чоры башланганда ук инде ул 100 банка ябарга өлгергән иде! Шул ук вакытта оныкларына да вакыт таба бит әле: алары исә тизрәк әбиләре янына кунакка килү җаен гына карыйлар. Лия Ильинична исә ике улының да читләргә китмичә, бәхетне туган шәһәрләрендә табуларына сөенә. Ә гаилә бергә булганда, җан да тыныч, эш тә көйле бара.

Сирень СӘМӘРХАНОВА




## ТАБИГАТЬ СЮРПРИЗЫ

**Богдашкино авылында яшәүче Ирина һәм Владимир Харитоновлар үзләренең йорт яны участокларындагы сюрпризларга күнгән инде.**

Узган ел аларның бакчасында рекордлы 48 сантиметр озынлыктагы кишер, быел исә кызларының яраткан мультсериал герое Микки Маус формасындагы бәрәңге үскән.

Харитоновлар бәрәңге уңышын җыеп алып, саклауга да куйганнар инде.

- Бормалы – сырмалы яшелчәләр элек тә очраштыргалый иде, әмма монысы безнең игътибарны аеруча җәлеп итте, - дип сөйли гаилә башлыгы. – Мила бик сөенде, чөнки ул Микки Маус турындагы мультфильмны бик ярата.

Өч яшьлек тиктормас могҗиза бәрәңге белән бик теләп фотога төште. Киләсе елга табигать аларга тагын нинди сюрприз алып килер икән, дип фаразлыйсы гына кала.

Маргарита ЛИТТА

# Кулларыннан куанып яши

УҢГАННАР

**Рөстәм Әбҗапбаровның Югары Нурлаттагы йорты–аның осталыгына һәйкәл диярге була, чөнки биредәге бар хезмәт тә аның куллары белән башкарылган.**

Йорт каршына җәелгән брусчаткадан башлана ул, аннан үзе эретеп ябыштырган тимер капка, үз куллары белән фундамент салган, кирпеч тезгән, ишек утырткан, базын казыган, идәнен цементлаган зур гараж китә. Арырак – ул эретеп ябыштырган беседка, поликарбонаттан бастырган теплица, ташлар һәм чәчәкләр уртасында саф суын бөркеп фонтан утыра. Инде йортның эченә керсәң, веранда төзү, аны вагонкалар белән эшләү, мунча ясау, аның мичен чыгару, су кертү, канализация үткәрү, эскәмияләрен ясау, идәненә плитә җәю һәм тагы әллә никадәр эшнең берсен дә акча түләп эшләтмәде Рөстәм. Аның бар эшкә дә кулы ятып торуын күреп дуслары да, тирә-күршеләре дә тел шартлата.

– Бер генә дә тик тора белмисең инде, тагы яңа эш башлаган, – диләр баш чайкап. Каян килгән аңа бу осталык – Рөстәм җавап урынына елмая гына. Яшьтән эш рәтен белеп үсә ул. Нурлаттагы фатирларын да шулай үзе ясаган иде бит ул. Күрәсең, сәләт – Ходайдан, тырышлык үзеннән килгәндер. Һәр яңа эшне үзләштерү барыбер күпмедер түземлек сорый бит. Кул эшләрендә генә түгел, үз хезмәтендә дә шулай җанын биреп, белеп эшләргә гадәтләнгән Рөстәм. Һөнәре – машина йөртүче, "Сельхозтехника", 547нче ПМК кебек оешмаларда эшләгән, соңгы 15 елын УТТ һәм "Нурлатавтотранс" җәмгыятендә вахта ташый. Нефтьчеләрнең эш графигы сәгатьләп кенә түгел, минуты-минутка туры килергә тиеш: буранмы, яңгырмы, адәм чыдамаслык эсселәрме – Рөстәм иртәнге 4тә аяк өстендә була, вахтасын җыеп, кайберәүләр әле йокысыннан гына уянганда озын юлга чыгып китә. Бер карасаң, мондый графикта булган кешенең үз йортында эшләргә вакыты да калмаска тиеш кебек.

– Кала, – ди Рөстәм. – Минем танышлар арасында үз йортлары белән яшәүчеләр шактый, ә йорт хуҗалыгы гел ир-ат кулы таләп итеп тора.

Шулайдыр, йортта эш һәркемгә җитә. Рөстәмнең улы Рузил да әтисенең эш ритмына яшьтән күнеп үсте, хуҗабикә Миннегөлгә дә тик торырга туры килми. Уңган ир янәшәсендә үзенә тиң булган хатын-кыз гына аның һәр башлангычын хуплап, кирәк чакта – ярдәм итеп яши ала. Әбҗапбаровлар әнә шулай үз нәселләрендә татулыклары, кунакчыллыклары белән дә сокландыралар әле. Ә быелгы отпускысында Рөстәмгә гомер булмаганча йорт эшен читкәрәк этеп торырга туры килде. Сәбәбе дә саллы иде: туй мәшәкатьләре белән үтте ялы. Ә үз куллары белән заманча ясаган йортта килен төшерү, кодалар китерү, кунаклар кабул итүнең ләззәтен гадәтенчә тыйнак кына елмаеп кичерде ул.

Сәкинә НУРУЛЛИНА




РӨСТӘМ ӘБҖАПБАРОВ ҮЗ ЙОРТЫНДА

# Каршы торырга һәрчак әзерләр



**2009 ел. 17 август – Назраньда теракт, 25 кеше үлә, 136 кеше тән җәрәхәте ала.**

**27 ноябрь – "Нева экспрессы" поезды һәлакәте теракт буларак бәяләнә. 28 кеше үлә, 95е яралана.**

**2011 ел. Мәскәүдәге Домодедово аэропортында террорчы бомба шартлата. 37 кеше һәлак була, 130ы тән җәрәхәте ала.**

**2013 ел. 29 декабрь – Волгоград вокзалында шартлау. 18 кеше һәлак була, 40ы яралана.**

**2015 ел. 14 сентябрьдә Тольятти каучук заводында шартлау була. Бер кеше үлә, ике кеше хастаханәгә озатыла...**

Терактларда һәрвакыт бер гаепсез кешеләр һәлак була. Экстремистларның һәм террорчыларның алдан уйланылган җинаятьләре көтмәгәндә һөҗүм итүгә исәпләнгән дә инде. Шуңа күрә мондый күренешләргә каршы тору өчен, стратегик мөһим объектлар төрле профилактика чаралары кулланалар. Оешма һәм учреждениеләрдәге стендлар, коллектив өйрәнү тренировкалары, янгын службасының предприятиеләрдәге эвакуация юлларын тикшерүе һәм башка чаралар – болар барысы да гадәттән тыш хәлләрдә кешеләрне дөрес карарлар кабул итәргә өйрәтүгә юнәлдерелгән.

Узган атнада "Нурлатнефтепродукт" базасында "Татнефтепродукт" холдинг компаниясе структур подразделениеләре ирекле янгын дружиналарының хәрби әзерлек смотр-ярышы булып узды.

– Без куркыныч җитештерү объектында эшлибез, һәм бу ярыш – безнең өчен бик әһәмиятле чара, – диде предприятиенең баш инженеры Василий Гаврилов. – Экстремизм һәм террорчылык очраклары булганда, дөрес эш итәргә өйрәнү өчен бездә барлык алымнар да кулланыла.

Биредә холдинг компаниясе структур предприятиеләреннән янгын машиналары һәм янгын мотопомпалары булган 10 команда көч сынашты. Мондый смотр-ярышларның максаты булып гамәли эшчәнлеккә әзерлекне билгеләү, ирекле янгын дружинасы әгъзаларының һөнәри дәрәҗәсен күтәрү, профессиональ янгын сүндерүчеләр белән предприятиенең ирекле янгын дружиналарының бердәм эш итүен көйләү тора. Ярышлар 5 этапта узды. Беренчесе – хәрби кием-салымны кию. Бу беренче карашка гына җиңел булып тоела. Ә катнашучыларга санаулы секундлар эчендә старт линиясеннән янгын постына чабып барып, брезент куртка, җилкә каешлы чалбар, карабинлы каеш, битлекле каска һәм пелерина, бияләй кияргә кирәк. Барысы да җентекләп тикшерелә: хәрби киемнең барлык төймәләре дә каптырылганмы, куртка якасы күтәрелгән һәм турайтылганмы, каеш борылмаганмы... Гомумән, жюри әгъзалары һәр биремнең үтәлешен җентекләп тикшерделәр, катнашучылар да ярышларга җитди карадылар: беркемнең дә штрафлы секундлар аласы килмәде. Алга куелган бурычларны барысы да үтәде, ә нурлатлылар, биремне 25 секунд эчендә башкарып, иң яхшылар буларак танылдылар. Беренче этаптагы уңыш, яисә үз җирләрендә чыгыш ясау булыштымы, "Нурлатнефтепродукт" командасы башка этапларда да лидерлыкны бирмәде. Әмма аннан бер атна элегрәк Казанда узган ягулык салу станцияләре операторлары арасындагы конкурста Нурлат нефтебазасының иң яхшы нәтиҗә күрсәтүен искә алсак, мондый чараларны үткәрү урынының әһәмияткә ия булмаганын күрербез. Иң мөһиме – үз эшеңне яхшы белү. Мондый стратегик предприятиедә бу икеләтә әһәмиятле. Шуңа күрә конкурста катнашучы "Нурлатнефтепродукт" хезмәткәрләре җитезлек тә, осталык та күрсәттеләр. Икенче этап – тревога буенча җыену һәм янгын автомобилендә юлга чыгу өчен алар янә иң яхшы вакыт – 26 секунд кына сарыф иттеләр. Су, янгын техникасыннан һава-механик күбек сиптерүдә дә яхшы нәтиҗә күрсәттеләр. Шулай итеп, нурлатлылар беренче урынга чыктылар.

– Бу чара безнең ирекле янгын дружиналарыбызның укуына нәтиҗә ясау, – диде ярышлардан соң "Татнефтепродукт холдинг компаниясе" ААҖ генераль директоры Рөстәм Сабиров. Шунда ук җиңүгә ирешкән нурлатлылар адресына мактау сүзләрен дә өстәде. – Нефтебаза әйбәт торышта, без аның теләсә нинди көтелмәгән хәлгә әзер булуын күрдек.

Янгын сагының Нурлат гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин әйтүенчә, экстремизм һәм терроризмны профилактикалау буенча чаралар район һәм шәһәрнең башка объектларында да үткәрелә.

– Районда терроризмга каршы комиссия эшли, аны район башлыгы Равил Кузюров җитәкли. Хокук саклау структуралары, МЧС, дини оешмалар вәкилләре катнашында үткән утырышларда Россиядә, республикада һәм районда килеп туган проблемалы мәсьәләләр карала. Стратегик әһәмиятле, массакүләм халык булган объектлар җитәкчеләренә әлеге объектларны саклау, предприятиенең барлык периметры буенча видеокүзәтү кертү, тревога сигналы кнопкасын булдыру кебек бурычлар йөкләнгән. Болардан тыш, мондый объектларда өйрәнү тренировкалары да үткәрелә. Болар барысы да шәһәрдә һәм районда экстремизм һәм терроризм очракларына юл куймас өчен эшләнә.

# Өйрәнү эвакуациясе ярдәм итә

Шәһәрнең 2нче мәктәп укучылары дәрес уртасында яңгыраган бер озын һәм ике кыска сигналны тәнәфескә чакырган кыңгырау тавышы белән бутамыйлар. Бу – эвакуация сигналы.

– Мәктәптәге өйрәнү эвакуациясе – теләсә нинди гадәттән тыш хәлләрдә балаларны саклау алымнарыннан берсе, – ди әлеге күренешне күзәтеп торган Нурлат шәһәренең ОНД баш белгече Әлмарис Талипов.

3, 4, 6, 7нче сыйныф укучылары укытучы озатуында сыйныф бүлмәсеннән тиз генә чыктылар һәм эвакуацион чыгу юлларына таба юнәлделәр. Бу мәктәптә алар 6ау, һәркайсына номер сугылган, иң әһәмиятлесе – һәр сыйныф эвакуация вакытында үз чыгу юлын белә. Шуңа күрә укучылар арасында каушап калу күзәтелми, алар тыныч, һәр сыйныф бер-бер артлы мәктәптән чыга бара. Мәктәп ишегалдында да ыгы-зыгы күренми – барысы да тезелешеп, җыелу урынына ашыгалар. Мондый чараларның биредә даими үткәрелүе күренеп тора.

– Без чиреккә бер тапкыр укучылар белән өйрәнү эвакуациясе уздырабыз, – ди мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары, хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык өчен җаваплы Гүзәл Бурлакова.

Бу көнне кече һәм урта сыйныф укучылары иң яхшы вакыт күрсәттеләр – шартлы куркыныч янау урынын 2 минут ярым эчендә ташлап киттеләр. Көз-яз көннәрендә җыену өчен 3 минут, кышын 5 минут бирелә. Сүз уңаеннан, кыш көне икенче смена укучылары арасында өйрәнү эвакуациясе тулы караңгылыкта диярлек үткәрелә – караңгы иртә төшә бит. Бу вакытта балалар стенадагы һәм эвакуацион чыгу юллары өстендәге күрсәткечләргә карап ориентлашалар.

– Өйрәнү эвакуациясе вакытында алынган күнекмәләр каушап калмаска ярдәм итә. Уку елының беренче көннәрендә без балалар белән куркынычсызлык буенча инструктажлар үткәрдек, – диде Гүзәл Бурлакова. – Өлкән сыйныф укучылары белән сыйныф сәгатьләре вакытында яшьләр экстремизмы һәм аның нәрсә белән янавы хакында сөйләшәбез. Безнең мәктәптә 10га якын милләт балалары белем ала. Укучыларда без төрле милләт кешеләренә ихтирам, толерантлык сыйфатлары тәрбиялибез. Хәзер "Экстремизмга – юк!" айлыгы бара, һәм без МЧС белән берлектә төрле чаралар үткәрәбез. Балаларга шикле предмет тапкан очракта үз-үзләрен ничек тотарга, таныш булмаган кешеләр үтенече белән мәктәпкә нинди дә булса пакетлар, төргәкләр алып килергә ярамаганлыгы хакында аңлатабыз.

Район мәктәпләренә МЧСның игътибары зур. Әлмарис Талипов әйтүенчә, эвакуация юллары, ут булмаганда фонарьларның, кисәтү билгеләренең булуы җентекләп тикшерелә.

– Шундый тикшерүләр вакытында мәктәп территориясендә чит транспорт чараларының булмаска тиешлеген аңлатабыз, яктыртуга игътибарны юнәлтәбез. Уку елы башына район мәктәпләре куркынычсызлык ягыннан яхшы әзерләнгәннәр, – ди ул. – Хәзер уку-укыту учреждениеләрендә "Укчы-мониторинг" программа-аппарат комплексын урнаштыру дәвам итә. Әлеге комплекс, мәктәптә янгын чыккан очракта, 125нче янгын частеның диспетчер службасында да автоматик рәвештә янгын сигнализациясе сигналы эшләп китүен тәэмин итә. Райондагы 43 мәктәпнең 20сендә бу комплекс урнаштырылган инде, ноябрь азагына кадәр ул башка мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында да булачак.

**Язмаларны Сирень СӘМӘРХАНОВА әзерләде**

## ШАРТЛАТКЫЧ ҖАЙЛАНМА ТАПКАН ОЧРАКТА



*• Шикле предметка юлыккан очракта, һичкичекмәстән эчке эшләр органнарының, ФСБ, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр бүлекләренең кизү службаларына, шәһәр хакимиятенең оператив кизү торучысына хәбәр итәргә. Тел.: 2-22-72, 112.*

*• Тапкан предметка якын килмәскә, кул белән тотмаска, башкаларны аның янына җибәрмәскә.*

*• Радиошартлаткычны хәрәкәткә китерергә сәләтле радио элемтәсе, кәрәзле телефоннар һәм башка радио чараларын куллануны булдырмаска.*

*• Хокук саклау органнары вәкилләренең килгәнен көтәргә һәм шикле предметның урынын күрсәтергә.*

*• Шартлау куркынычы булган предметны аның табылу урынында бары тик МВД, ФСБ, МЧС белгечләре генә зарарсызландыра ала.*

## ӘГӘР СЕЗНЕ ЗАЛОЖНИКЛЫККА АЛСАЛАР



*• Үз-үзегезне кулга алыгыз, тынычланыгыз, паникага бирелмәгез.*

*• Сезне урлаучыларга карата нәфрәт һәм илтифатсызлык күрсәтмәгез.*

*• Баштан ук террористның барлык күрсәтмәләрен үтәгез.*

*• Үз-үзегезне тотышыгыз белән террористларның игътибарын җәлеп итмәгез, актив каршылык күрсәтмәгез.*

*• Әгәр качу уңышына тулы ышанычыгыз булмаса, качарга тырышмагыз.*

*• Үзегезне начар хис итүегез турында әйтегез.*

*• Террористлар турында күбрәк мәгълүмат истә калдырыгыз.*

*• Үзегезнең кайдалыгыгызны билгеләргә тырышыгыз.*


*• Рухи һәм физик активлыкны саклагыз. Шуны истә тотыгыз: хокук саклау органнары сезне коткару өчен барысын да эшли.*

*• Ашаудан баш тартмагыз. Ул көч һәм сәламәтлекне сакларга ярдәм итә.*

*• Тәрәзә, ишектән, террорчыларның үзләреннән ераграк урын алыгыз. Бу бинаны штурмлау башланган очракта, җинаятьчеләргә юнәлгән снайпер пуляларыннан саклану өчен кирәк.*

*• Бинаны штурмлаганда битегез белән аска, кулларыгызны баш артына куеп, идәнгә ятыгыз.*

## ТЕРАКТ КУРКЫНЫЧЫ ВАКЫТЫНДА



*• Ашыгыч эвакуациягә әзерләнегез. Моның өчен сумкага документларыгызны, акча, кыйммәтле әйберләрегезне, бераз ашамлыклар тутырыгыз.*

*• Балкон һәм лоджиялардән ягулык-майлау һәм җиңел янучан материалларны алыгыз.*

*• Беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен йод, бинт, мамык һәм башка медчаралар әзерләгез.*

*• Кешеләр күп җыелган урыннарны әйләнеп узыгыз.*

*• Җәмәгать транспортларыннан сирәк кулланыгыз.*

*• Балаларны һәм олы кешеләрне башка торак пунктка озату кулай.*

*• Радио һәм телевизор һәрвакыт эшләп торсын.*

*• Ашамлыклар һәм су запасы булдырыгыз.*

*• Хокук саклау органнарына ашыгыч мәгълүмат җибәрү өчен телефоннар исемлеге һәрвакыт кул астыгызда булсын.*

